| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.11.2019 Казан шәһәре № 10-95/кс

2020 елга «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчәргә яраклы суга, су агызуга, агынты суларны транспортлауга һәм эчәргә яраклы суны транспортлауга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Шушы карар кушымтасына туры китереп, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчә торган суга, су агызуга, агынты суларны транспортлауга һәм эчә торган су транспортлауга календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2020 елның 1 гыйнварыннан 2020 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә булачак.

3. Салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартларына туры китереп, ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турындагы карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 20.11.2019 № 10-95/кс карарына кушымта

# Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчә торган суга 2020 ел өчен календарь буенча бүленгән тарифлар

| № т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб м. | | Су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб м. | | Агынты суларны транспортлаган өчен тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | Эчәргә яраклы суны транспортлауга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | башлана 01.01.2020 тәмамлана 30.06.2020 | башлана 01.07.2020 тәмамлана 31.12.2020 | башлана 01.01.2020 тәмамлана 30.06.2020 | башлана 01.07.2020 тәмамлана 31.12.2020 | башлана 01.01.2020 тәмамлана 30.06.2020 | башлана 01.07.2020 тәмамлана 31.12.2020 | башлана 01.01.2020 тәмамлана 30.06.2020 | башлана 01.07.2020 тәмамлана 31.12.2020 |
| | «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге | | | | | | | | |
| 1 | «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | | | | | |
| 1.1 | «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге кулланучылары (тарифлар НДС исәпкә алмыйча күрсәтелде) | | | | | 15,27 | 15,27 | 4,09 | 4,09 |
| 1.2 | «Казан шәһәре» муниципаль берәмлегенең «Салават Күпере» торак районы кулланучылары | | | | | | | | |
| 1.2.1 | Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде)* | 20,56 | 21,38 | 19,58 | 20,36 | | | | |
| 1.2.2 | Бүтән кулланучылар (тарифлар НДС исәпкә алмыйча күрсәтелде) | 17,13 | 17,82 | 16,32 | 16,97 | | | | |
| | Яшел Үзән муниципаль районы | | | | | | | | |
| 1.3 | Зеленодольск муниципаль районы кулланучылары – Дубровка «Западная Ореховка», Дубровка «Центральная ореховка» һәм Дубровка «Загородный | | | | | 4,61 | 4,79 | | |

| № т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб м. | | Су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб м. | | Агынты суларны транспортлаган өчен тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | Эчәргә яраклы суны транспортлауга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | башлана 01.01.2020 тәмамлана 30.06.2020 | башлана 01.07.2020 тәмамлана 31.12.2020 | башлана 01.01.2020 тәмамлана 30.06.2020 | башлана 01.07.2020 тәмамлана 31.12.2020 | башлана 01.01.2020 тәмамлана 30.06.2020 | башлана 01.07.2020 тәмамлана 31.12.2020 | башлана 01.01.2020 тәмамлана 30.06.2020 | башлана 01.07.2020 тәмамлана 31.12.2020 |
| | клуб» коттедж бистәләре өчен (тарифлар НДС башка күрсәтелгән) | | | | | | | | |
| 1.4 | Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге кулланучылары (тарифлар НДС башка күрсәтелгән) | | | | | 4,10 | 4,10 | 2,27 | 2,27 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын тормышка ашыру максатларында аерып чыгарыла

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге